ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

17 март 2026 ел

**КАРАР**

№ 2548

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучылар һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр өчен өстәмә социаль ярдәм чаралары турында

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләргә өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү максатларында, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 2025 елның 3 декабрендәге 3/5 номерлы Карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның түбәндәге категорияләре өчен бер тапкыр түләүсез кайнар ризык билгеләргә:

1) 1-4 сыйныф укучылары өчен: бер укучыга түләүсез туклану бәясе – 77,76 сум;

2) балигъ булмаган өч һәм аннан күбрәк балалы гаиләләрдә тәрбияләнүче 5-11 сыйныф укучылары өчен бер укучыга түләүсез туклану бәясе – 92,24 сум.

2. Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның түбәндәге категорияләре өчен ике тапкыр түләүсез кайнар ризык билгеләргә:

1) инвалид балалар, сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикле балалар өчен: бер укучыга туклану бәясе 1-4 сыйныфлар өчен – 134,06 сум; 5-11 сыйныфлар өчен – 136,10 сум;

2) Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсе хезмәткәрләренең, Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсенең федераль дәүләт граждан

хезмәткәрләренең, Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсендә эшләүчеләрнең балалары өчен: бер укучыга туклану бәясе 1-4 сыйныфлар өчен – 134,06 сум; 5-11 сыйныфлар өчен – 136,10 сум;

3) «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Россия милли гвардия гаскәрләренең ведомстводан тыш сак идарәсе» ФДКУ филиалы – Яр Чаллы шәһәре буенча ведомстводан тыш сак бүлеге хезмәткәрләренең, граждан персоналының балалары өчен: бер укучыга туклану бәясе 1-4 сыйныфлар өчен – 134,06 сум; 5-11 сыйныфлар өчен – 136,10 сум;

4) Сириядән килгән, шул исәптән Россия территориясендә вакытлыча яшерену урыны алган, Яр Чаллы шәһәрендә вакытлыча урнаштырылган качакларның балалары өчен: 1-4 сыйныфлар өчен бер укучыга туклану бәясе – 134,06 сум; 5-11 сыйныфлар өчен – 136,10 сум;

5) Татарстан Республикасы буенча Росгвардия идарәсенең Яр Чаллы шәһәре «Тайфун» ОМОН хезмәткәрләренең балалары өчен: 1-4 сыйныфлар өчен бер укучыга туклану бәясе – 134,06 сум; 5-11 сыйныфлар өчен – 136,10 сум;

6) махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның балалары өчен: бер укучыга туклану бәясе 1-4 сыйныфлар өчен – 134,06 сум; 5-11 сыйныфлар өчен – 136,10 сум;

7) махсус хәрби операциядә катнашканда яралану сәбәпле дәвалануда булган гражданнарның балалары өчен: бер укучыга туклану бәясе 1-4 сыйныфлар өчен – 134,06 сум; 5-11 сыйныфлар өчен – 136,10 сум;

8) махсус хәрби операциядә катнашу чорында алган авыру аркасында яки хәрби травма аркасында 1 төркем инвалид булган гражданнарның балалары өчен: бер укучыга туклану бәясе 1-4 сыйныфлар өчен – 134,06 сум; 5-11 сыйныфлар өчен – 136,10 сум;

9) махсус хәрби операция зонасында һәлак булган яки хәбәрсез югалган гражданнарның балалары өчен: бер укучыга туклану бәясе 1-4 сыйныфлар өчен – 134,06 сум; 5-11 сыйныфлар өчен – 136,10 сум.

3. Мәктәпкәчә төп белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль мәктәпкәчә учреждениеләргә (балалар бакчаларына) йөрүче балаларны карау һәм тәрбияләү өчен түләүдән азат итәргә:

1) Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсе хезмәткәрләренең, Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсенең федераль дәүләт граждан хезмәткәрләрнең, Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсендә эшләүчеләрнең балаларының ата-аналарын;

2) «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Россия милли гвардия гаскәрләренең ведомстводан тыш сак идарәсе» ФДКУ филиалы – Яр Чаллы шәһәре буенча ведомстводан тыш сак бүлеге хезмәткәрләренең, граждан персоналының балаларының ата-аналарын;

3) Сириядән килгән, шул исәптән Россия территориясендә вакытлыча яшерену урыны алган, Яр Чаллы шәһәрендә вакытлыча урнаштырылган качак балаларының ата-аналарын;

4) Татарстан Республикасы буенча Росгвардия идарәсенең Яр Чаллы шәһәре «Тайфун» ОМОН хезмәткәрләре балаларының ата-аналарын;

5) махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның балаларының ата-аналарын;

6) махсус хәрби операциядә катнашканда яралану сәбәпле дәвалануда булган гражданнарның балаларының ата-аналарын;

7) махсус хәрби операциядә катнашу чорында алган авыру аркасында яки хәрби травма аркасында 1 төркем инвалид булган гражданнарның балаларының ата-аналарын;

8) махсус хәрби операция зонасында һәлак булган яки хәбәрсез югалган гражданнарның балаларының ата-аналарын.

4. Расларга:

1) Яр Чаллы шәһәренең муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү тәртибе турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) Яр Чаллы шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләргә өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү тәртибе турында нигезләмәне, 2 нче кушымтада каралганча.

5. Башкарма комитетның финанс идарәсенә әлеге карарның 1-3 пунктларында күрсәтелгән чыгымнарны финанслауны 2026 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында түбәндәге бүлекләр (бүлекчәләр) буенча каралган акчалар чикләрендә тәэмин итәргә:

- 10.04 «Гаиләне һәм балачакны саклау» 159 822 660,00 сум (бер йөз илле тугыз миллион сигез йөз егерме ике мең алты йөз алтмыш сум ноль тиен) күләмендә, шул исәптән 0300305110 максатчан статьясы буенча 64 855 560,00 сум (алтмыш дүрт миллион сигез йөз илле биш мең биш йөз алтмыш сум ноль тиен) күләмендә һәм 0340325510 максатчан статьясы буенча 94 967 100,00 сум (туксан дүрт миллион тугыз йөз алтмыш җиде мең бер йөз сум ноль тиен) күләмендә;

- 07.02 «Гомуми белем бирү» 420 306 100,00 сум (дүрт йөз егерме миллион өч йөз алты мең бер йөз сум ноль тиен) күләмендә;

- 07.01 «Мәктәпкәчә белем бирү» 53 840 000,00 сум (илле өч миллион сигез йөз кырык мең сум ноль тиен) күләмендә.

6. Башкарма комитетның мәгариф идарәсенә тәэмин итәргә:

1) Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформадан (алга таба – ЕЦП) файдаланып, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә һәм ЕЦП операторы билгеләгән форматлар нигезендә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында мәгълүмат җибәрү;

2) ЕЦПдан файдаланып, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә һәм ЕЦП операторы билгеләгән форматлар нигезендә мәгълүмат алу.

7. Башкарма комитет Карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

1) 2025 елның 26 гыйнварында Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган, 2025 елның 29 гыйнварында «Челнинские известия» газетасының 6 нчы санында

бастырып чыгарылган «Яр Чаллы шәһәре муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучылар һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр өчен өстәмә социаль ярдәм чаралары турында» 2025 елның 23 гыйнварындагы 361 номерлы;

2) 2025 елның 18 июнендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган, 2025 елның 18 июнендә «Челнинские известия» газетасының 42 нче санында бастырып чыгарылган «Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучылар һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр өчен өстәмә социаль ярдәм чаралары турында» 2025 елның 23 гыйнварындагы 361 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 9 июнендәге 4118 номерлы;

3) 2025 елның 9 июлендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган, 2025 елның 9 июлендә «Челнинские известия» газетасының 48 нче санында бастырып чыгарылган «Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучылар һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр өчен өстәмә социаль ярдәм чаралары турында» 2025 елның 23 гыйнварындагы 361 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 4 июлендәге 4907 номерлы;

4) 2025 елның 7 ноябрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган, 2025 елның 7 ноябрендә «Челнинские известия» газетасының 82 нче санында бастырып чыгарылган «Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучылар һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр өчен өстәмә социаль ярдәм чаралары турында» 2025 елның 23 гыйнварындагы 361 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 31 октябрендәге 8921 номерлы;

5) 2025 елның 10 декабрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган, 2025 елның 10 декабрендә «Челнинские известия» газетасының 91 нче санында бастырып чыгарылган «Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучылар һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр өчен өстәмә социаль ярдәм чаралары турында» 2025 елның 23 гыйнварындагы 361 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 5 декабрендәге 10210 номерлы.

8. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

9. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» вакытлы матбугат басмаларында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

10. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2026 елның 17 мартындагы
2548 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү тәртибе турында
нигезләмә

## 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Яр Чаллы шәһәренең муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга (алга таба – укучылар) өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү тәртибе турында нигезләмә «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 2025 елның 3 декабрендәге 3/5 номерлы Карары нигезендә эшләнде һәм укучылар өчен түләүсез туклануны оештыру рәвешендә социаль ярдәм чаралары күрсәтү тәртибен билгели.

2. Бер тапкыр түләүсез кайнар ризык бирелә:

1) 1-4 сыйныф укучылары өчен;

2) балигъ булмаган өч һәм аннан күбрәк балалы гаиләләрдә тәрбияләнүче 5-11 сыйныф укучылары өчен.

3. Ике тапкыр түләүсез кайнар ризык бирелә:

1) инвалид балалар өчен, сәламәтлегә буенча мөмкинлекләре чикле балалар өчен;

2) Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсе хезмәткәрләренең, Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсенең федераль дәүләт граждан хезмәткәрләренең, Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсендә эшләүчеләрнең балалары өчен;

3) «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Россия милли гвардия гаскәрләренең ведомстводан тыш сак идарәсе» ФДКУ филиалы – Яр Чаллы шәһәре буенча ведомстводан тыш сак бүлеге граждан персоналының, хезмәткәрләренең балалары өчен;

4) Сириядән килгән, шул исәптән Россия территориясендә вакытлыча яшерену урыны алган, Яр Чаллы шәһәрендә вакытлыча урнаштырылган качакларның балалары өчен;

5) Татарстан Республикасы буенча Росгвардия идарәсенең Яр Чаллы шәһәре «Тайфун» ОМОН хезмәткәрләренең балалары өчен;

6) махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның балалары өчен;

7) махсус хәрби операциядә катнашканда яралану сәбәпле дәвалануда булган гражданнарның балалары өчен;

8) махсус хәрби операциядә катнашу чорында алган авыру аркасында яки хәрби травма аркасында 1 төркем инвалид булган гражданнарның балалары өчен;

9) махсус хәрби операция зонасында һәлак булган яки хәбәрсез югалган гражданнарның балалары өчен.

4. Махсус медицина күрсәткечләре буенча өйдә белем алучылар өчен (инвалид балалар өчен, сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикле балалар өчен) түләүсез ике тапкыр туклануны ике тапкыр туклану бәясендәге акчалата компенсация белән алмаштыру тәэмин ителә.

2 бүлек. Муниципаль гомуми белем бирү оешмасында туклануны оештыру

5. Муниципаль гомуми белем бирү оешмасында укучыларның туклануын оештыру өчен, составы гомуми белем бирү оешмасы директорының приказы белән раслана торган туклануны оештыру буенча комиссия (алга таба – комиссия) төзелә. Комиссия составына гомуми мәктәп ата-аналар комитеты вәкиле кертелә. Комиссиянең бер әгъзасы укучыларның туклануын оештыру өчен җаваплы итеп билгеләнә. Комиссия әгъзаларының гомуми саны кимендә биш кеше тәшкил итә.

6. Гомуми белем бирү оешмасы директоры тәэмин итә:

1) гамәлдәге законнар нигезендә укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыруны һәм бюджет акчаларыннан максатчан файдалануны, түләүсез кайнар ризык белән тукланучы укучыларның факттагы санын исәпкә алуны;

2) өйдә белем алучы инвалид балалар һәм сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикле балалар өчен ике тапкыр туклану бәясенә акчалата эквивалентта компенсация бирүне оештыруны;

3) ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) документлар кабул итү эшен оештыруны.

7. Укучыларның ата-аналарыннан (законлы вәкилләреннән) түләүсез кайнар ризык белән туклану турында гаризаларны кабул итү электрон төрдә гомуми белем бирү оешмасының электрон почтасына яки уку урыны буенча гомуми белем бирү оешмасында шәхсән гамәлгә ашырыла.

8. Түләүсез туклану түбәндәге документлар нигезендә башкарыла:

1) балигъ булмаган өч һәм аннан күбрәк балалы гаиләләрдә тәрбияләнүче 5-11 сыйныф укучылары өчен:

- күп балалы гаилә таныклыгының күчермәсе яки балаларның туу турында таныклык күчермәләре;

- балигъ булган баланың көндезге формада уку урыныннан белешмә;

2) инвалид балалар өчен, сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикле балалар өчен:

- инвалидлык турында белешмә күчермәсе;

- психологик-медицина-педагогик комиссия бәяләмәсенең күчермәсе;

- компенсация күчерү өчен, исәп-хисап счетын күрсәтеп, акчалата компенсация алуга гариза (өйдә белем алучы инвалид балаларның һәм сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикле балаларның ата-аналары өчен);

3) Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсе хезмәткәрләренең, Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсенең федераль дәүләт граждан хезмәткәрләренең, Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсендә эшләүчеләрнең балалары өчен:

- Эчке эшләр министрлыгының хезмәт таныклыгы күчермәсе яки Яр Чаллы шәһәре буенча Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы идарәсе хезмәткәренең, федераль дәүләт граждан хезмәткәренең, эшләүченең эш урыныннан белешмәсе;

4) «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Россия милли гвардия гаскәрләренең ведомстводан тыш сак идарәсе» ФДКУ филиалы – Яр Чаллы шәһәре буенча ведомстводан тыш сак бүлеге хезмәткәрләренең, граждан персоналының балалары өчен:

- «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Россия милли гвардия гаскәрләренең ведомстводан тыш сак идарәсе» ФДКУ филиалы – Яр Чаллы шәһәре буенча ведомстводан тыш сак бүлеге хезмәткәрләренең хезмәт таныклыгы күчермәсе яки «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Россия милли гвардия гаскәрләренең ведомстводан тыш сак идарәсе» ФДКУ филиалы – Яр Чаллы шәһәре буенча ведомстводан тыш сак бүлеге граждан персоналының эш урыныннан белешмә;

5) Сириядән килгән, шул исәптән вакытлыча яшерену урыны статусында Россия территориясендә булган, Яр Чаллы шәһәрендә вакытлыча урнаштырылган качакларның балалары өчен:

- качак таныклыгы яки Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча яшеренү урыны бирү турында таныклык күчермәсе;

6) Татарстан Республикасы буенча Росгвардия идарәсенең Яр Чаллы шәһәре «Тайфун» ОМОН хезмәткәрләренең балалары өчен:

- Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәте хезмәткәренең хезмәт таныклыгы күчермәсе яки Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Яр Чаллы шәһәрендәге идарәсе хезмәткәренең эш урыныннан белешмә;

7) махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның балалары өчен:

- ананың/атаның паспорт күчермәсе;

- баланың туу турында таныклык күчермәсе;

- кызлыкка/уллыкка алу өчен документлар, ата булуны билгеләү турында таныклык, опека билгеләү турында карар;

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданнарының Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашу фактын билгеләү тәртибе турында» 2024 елның 9 октябрендәге 1354 номерлы Карары нигезендә гражданнарны махсус хәрби операциядә катнашу өчен җибәргән (җәлеп иткән) федераль башкарма хакимият органнары (федераль дәүләт органнары) тарафыннан бирелә торган белешмә;

- язылышу турында таныклык күчермәсе (ир белән хатын балаларын бергә тәрбияләгән очракта);

8) махсус хәрби операциядә катнашканда яралану сәбәпле дәвалануда булган гражданнарның балалары өчен:

- ананың/атаның паспорт күчермәсе;

- язылышу турында таныклык күчермәсе (ир белән хатын балаларын бергә тәрбияләгән очракта);

- баланың туу турында таныклык күчермәсе;

- кызлыкка/уллыкка алу өчен документлар, ата булуны билгеләү турында таныклык, опека билгеләү турында карар;

- махсус хәрби операциядә катнашкан вакытта яралануны раслаучы белешмә күчермәсе;

9) махсус хәрби операциядә катнашу чорында алган авыру аркасында яки хәрби травма аркасында 1 төркем инвалид булган гражданнарның балалары өчен:

- ананың/атаның паспорт күчермәсе;

- язылышу турында таныклык күчермәсе (ир белән хатын балаларын бергә тәрбияләгән очракта);

- баланың туу турында таныклык күчермәсе;

- кызлыкка/уллыкка алу өчен документлар, ата булуны билгеләү турында таныклык, опека билгеләү турында карар;

- атаның/ананың махсус хәрби операциядә катнашуын раслаучы документ күчермәсе;

- хәрби билет күчермәсе;

- инвалидлык турында белешмә күчермәсе;

10) махсус хәрби операция зонасында һәлак булган яки хәбәрсез югалган гражданнарның балалары өчен:

- ананың/атаның паспорт күчермәсе;

- язылышу турында таныклык күчермәсе (ир белән хатын балаларын бергә тәрбияләгән очракта);

- баланың туу турында таныклык күчермәсе;

- кызлыкка/уллыкка алу өчен документлар, ата булуны билгеләү турында таныклык, опека билгеләү турында карар;

- махсус хәрби операциядә катнашучының үлеме турында таныклык күчермәсе яки махсус хәрби операциядә катнашучыны хәбәрсез югалган дип тануны раслаучы документ күчермәсе;

9. Укучыларның туклануын оештыру өчен җаваплы зат, мәктәп укучысы картасын ясау өчен, укучыны реестрга кертү өчен кирәкле мәгълүматларны (фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, җенесе, туу турында таныклык, паспорт (булганда) мәгълүматлары (биргән ил, РФ субъекты, серия, номер һәм бирү датасы), фотография, аерып күрсәтелгән «Карта өчен фото» фрагменты яки фотога төшерүдән баш тартканда контур) кертеп, укучы белем бирү оешмасына укырга кергәннән соң 10 эш көне эчендә «Татарстан Республикасында электрон мәгариф» дәүләт мәгълүмат системасында укучының шәхси делосын тутыру эшен оештыруны тәэмин итә.

10. Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның балаларының ата-аналарына (законлы вәкилләренә) социаль ярдәм чаралары күрсәтү өчен, атаның/ананың махсус хәрби операциядә катнашуын раслаучы документларның күчермәләрен ел саен яңартырга кирәк.

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы

Г.А. Шәфыйкова

Башкарма комитетның
2026 елның 17 мартындагы
2548 номерлы карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләргә өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү тәртибе турында нигезләмә

1. Әлеге Яр Чаллы шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләргә өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү тәртибе турында нигезләмә «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына  Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 2025 елның 3 декабрендәге 3/5 номерлы Карары нигезендә эшләнде һәм балаларны карау һәм тәрбияләү өчен түләүдән азат итү рәвешендә социаль ярдәм чаралары күрсәтү тәртибен билгели.

2. Яр Чаллы шәһәре муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүче балаларны карау һәм тәрбияләү өчен түләүдән азат итү рәвешендә өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтелә:

1) Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсе хезмәткәрләренең, Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсенең федераль дәүләт граждан хезмәткәрләрнең, Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсендә эшләүчеләрнең балаларының ата-аналарына;

2) «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Россия милли гвардия гаскәрләренең ведомстводан тыш сак идарәсе» ФДКУ филиалы – Яр Чаллы шәһәре буенча ведомстводан тыш сак бүлеге хезмәткәрләренең, граждан персоналының балаларының ата-аналарына;

3) Сириядән килгән, шул исәптән Россия территориясендә вакытлыча яшерену урыны алган, Яр Чаллы шәһәрендә вакытлыча урнаштырылган качак балаларның ата-аналарына;

4) Татарстан Республикасы буенча Росгвардия идарәсенең Яр Чаллы шәһәре  «Тайфун» ОМОН хезмәткәрләре балаларының ата-аналарына;

5) махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның балаларының ата-аналарына;

6) махсус хәрби операциядә катнашканда яралану сәбәпле дәвалануда булган гражданнарның балалары өчен;

7) махсус хәрби операциядә катнашу чорында алган авыру аркасында яки хәрби травма аркасында 1 төркем инвалид булган гражданнарның балалары өчен;

8) махсус хәрби операция зонасында һәлак булган яки хәбәрсез югалган гражданнарның балалары өчен.

3. Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе җитәкчесе тәэмин итә:

1) әлеге нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән балаларны карауны һәм тәрбияләүне;

2) ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) документлар кабул итү эшен оештыруны.

4. Тәрбияләнүчеләрнең ата-аналарыннан (законлы вәкилләреннән) баланы карау һәм тәрбияләү өчен түләүдән азат итү турында гаризаларны кабул итү электрон төрдә муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең электрон почтасына яки уку урыны буенча муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә шәхсән гамәлгә ашырыла.

5. Балаларны карау һәм тәрбияләү өчен түләүдән азат итү түбәндәге документлар нигезендә башкарыла:

1) Яр Чаллы шәһәре буенча Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы идарәсе хезмәткәрләренең, Яр Чаллы шәһәре буенча Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы идарәсенең федераль дәүләт граждан хезмәткәрләрнең балалары өчен:

- Эчке эшләр министрлыгының хезмәт таныклыгы күчермәсе яки Яр Чаллы шәһәре буенча Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы идарәсе хезмәткәренең, федераль дәүләт граждан хезмәткәренең, эшләүченең эш урыныннан белешмәсе;

2) «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Россия милли гвардия гаскәрләренең ведомстводан тыш сак идарәсе» ФДКУ филиалы – Яр Чаллы шәһәре буенча ведомстводан тыш сак бүлеге хезмәткәрләренең, граждан персоналының балалары өчен:

- «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Россия милли гвардия гаскәрләренең ведомстводан тыш сак идарәсе» ФДКУ филиалы – Яр Чаллы шәһәре буенча ведомстводан тыш сак бүлеге хезмәткәрләренең хезмәт таныклыгы күчермәсе яки «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Россия милли гвардия гаскәрләренең ведомстводан тыш сак идарәсе» ФДКУ филиалы – Яр Чаллы шәһәре буенча ведомстводан тыш сак бүлеге граждан персоналының эш урыныннан белешмәсе;

3) Сириядән килгән, шул исәптән Россия территориясендә вакытлыча яшерену урыны алган, Яр Чаллы шәһәрендә вакытлыча урнаштырылган качакларның балалары өчен:

- качак таныклыгы яки Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча яшерену урыны бирү турында таныклык күчермәсе;

4) Татарстан Республикасы буенча Росгвардия идарәсенең Яр Чаллы шәһәре «Тайфун» ОМОН хезмәткәрләренең балалары өчен:

- Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәте хезмәткәренең хезмәт таныклыгы күчермәсе яки Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Яр Чаллы шәһәрендәге идарәсе хезмәткәренең эш урыныннан белешмә;

5) махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның балалары өчен:

- ананың/атаның паспорт күчермәсе;

- балаларның туу турында таныклык күчермәсе;

- кызлыкка/уллыкка алу өчен документ яки ата булуны билгеләү турында таныклык, яки опека билгеләү турында карар;

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданнарының Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашу фактын билгеләү тәртибе турында» 2024 елның 9 октябрендәге 1354 номерлы Карары нигезендә гражданнарны махсус хәрби операциядә катнашу өчен җибәргән (җәлеп иткән) федераль башкарма хакимият органнары (федераль дәүләт органнары) тарафыннан бирелә торган белешмә;

- язылышу турында таныклык күчермәсе (ир белән хатын балаларын бергә тәрбияләгән очракта).

6) махсус хәрби операциядә катнашканда яралану сәбәпле дәвалануда булган гражданнарның балалары өчен:

- ананың/атаның паспорт күчермәсе;

- язылышу турында таныклык күчермәсе (ир белән хатын балаларын бергә тәрбияләгән очракта);

- баланың туу турында таныклык күчермәсе;

- кызлыкка/уллыкка алу өчен документлар, ата булуны билгеләү турында таныклык, опека билгеләү турында карар;

- яралануның махсус хәрби операциядә катнашкан вакытта булуын раслаучы белешмә күчермәсе;

7) махсус хәрби операциядә катнашу чорында алган авыру аркасында яки хәрби травма аркасында 1 төркем инвалид булган гражданнарның балалары өчен:

- ананың/атаның паспорт күчермәсе;

- язылышу турында таныклык күчермәсе (ир белән хатын балаларын бергә тәрбияләгән очракта);

- баланың туу турында таныклык күчермәсе;

- кызлыкка/уллыкка алу өчен документлар, ата булуны билгеләү турында таныклык, опека билгеләү турында карар;

- атанын/ананың махсус хәрби операциядә катнашуын раслаучы документ күчермәсе;

- хәрби билет күчермәсе;

- инвалидлык турында белешмә күчермәсе;

8) махсус хәрби операция зонасында һәлак булган яки хәбәрсез югалган гражданнарның балалары өчен:

- ананың/атаның паспорт күчермәсе;

- язылышу турында таныклык күчермәсе (ир белән хатын балаларын бергә тәрбияләгән очракта);

- баланың туу турында таныклык күчермәсе;

- кызлыкка/уллыкка алу өчен документлар, ата булуны билгеләү турында таныклык, опека билгеләү турында карар;

- махсус хәрби операциядә катнашучының үлеме турында таныклык күчермәсе яки махсус хәрби операциядә катнашучының хәбәрсез югалуын тануны раслаучы документ күчермәсе.

6. Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның балаларының ата-аналарына (законлы вәкилләренә) социаль ярдәм чаралары күрсәтү өчен, атанын/ананың махсус хәрби операциядә катнашуын раслаучы документларның күчермәләрен ел саен яңартырга кирәк.

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы

Г.А. Шәфыйкова